**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 № 56

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 30.09.2013 ел, № 892 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр, субсидияләрне бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актларга, шул исәптән юридик затларга, шәхси эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне житештерүче физик затларга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 1492 номерлы карары нигезендә (Ред.30.12.2020); Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 ел өчен һәм бурычларына финанс, казначылык һәм республика салым органнарының 2021 елга 04.01.2021, № ПР-3 номерлы беркетмәсе нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 30 сентябрендәге 892 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын бирү турында» карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә 2.1.пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«-салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч булмау турында белешмәләр. Мәгълүматлар РФ Федераль салым хезмәтеннән ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән соратып алына».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин